# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Касай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**от 14.11.2024** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Касай торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:
«2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Касай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле киткәннәр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, хатыннары, балигъ булмаган балаларыннан) тыш,яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 600 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

«1. Торак пункт территориясен (үләннәрне һәм чүп үләннәрен чабу, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү: Касай авылында дизель ягулыгы, дизель мае, ягулык-майлау материаллары, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчының хезмәт шартнамәсе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

2. Касай авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Үзәк урамы буенча юллар һәм ком сатып алу һәм салу һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).».

3. Су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә

торган су җыю манараларының су белән тәэмин итү һәм су түгү системасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу; җирлекне су белән тәэмин итү (тирәнлек насосларын сатып алу һәм ремонтлау, суүткәргеч челтәрен ремонтлау) һәм су белән тәэмин итүне карап тоту буенча башка чыгымнар).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 56 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 30 кеше, бу 53,57 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 30 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Касай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле киткәннәр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, хатыннары, балигъ булмаган балаларыннан) тыш,яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

«1. Торак пункт территориясен (үләннәрне һәм чүп үләннәрен чабу, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү: Касай авылында дизель ягулыгы, дизель мае, ягулык-майлау материаллары, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчының хезмәт шартнамәсе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

2. Касай авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Үзәк урамы буенча юллар һәм ком сатып алу һәм салу һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).».

3. Су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм

ремонтлау (су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган су җыю манараларының су белән тәэмин итү һәм су түгү системасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу; җирлекне су белән тәэмин итү (тирәндек насосларын сатып алу һәм ремонтлау, суүткәргеч челтәрен ремонтлау) һәм су белән тәэмин итүне карап тоту буенча башка чыгымнар).

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
авыл җирлеге Башлыгы Х.Л.ЗАКИРОВ